# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**№ 4** **11.12.2019 ел**

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль
районының Иске Карамалы авыл җирлеге составына керүче
Түреш торак пунктына 2020 елда гражданнарның
үзара салымын кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Иске Карамалы авыл җирлеге Түреш торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Түреш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым кертергә. Көндезге формада укучы студентларга, 1 һәм 2 төркем инвалидларга, Әфганстанда хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга һәм локаль конфликтлардагы хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

- Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү;
- Халыкның ялын оештыру һәм мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру;
- Җирлек территориясендә физик культура, мәктәп спорты һәм массакүләм спорт үсеше өчен шартлар тудыру, җирлекнең рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру;
- Җирлектә рәсми мәдәни-массакүләм чараларын оештыру;
- Авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру;
- Урам-юл челтәре элементларына, җирлек чикләрендә планлаштыру структурасы элементларына исемнәр бирү;
- Каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аерым җыю) һәм транспортлау эшчәнлеген оештыруда катнашу;
- Оештыру ритуаль хезмәтләр һәм карап тоту урыннар күмү;
- Оешма чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу;
- Җирлек торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;
- Җирлек халкының массакүләм ял итү өчен шартлар тудыру һәм халыкның массакүләм ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру, шул исәптән гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр полосаларына иректе үтүен тәэмин итү.
- Җирлекләрнең территориаль планлаштыру документларын әзерләү һәм раслау;
- Җирлек территориясендә яшәүче күзәтүчесез хайваннарны тоту һәм карап тоту чараларын тормышка ашыру.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда, Мөслим муниципаль районы рәсми сайтының http/ muslumovo.tatarstan.ru веб-адресына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга һәм Мөслим муниципаль районы, Түреш авылы,

Лесная урамы, 30а йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Иске Карамалы авыл җирлеге башлыгы И.Н.Кәримов